# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3; 2013, № 1, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның сигезенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 15 статьяның 12 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 18 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
“$1^1$. Җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре яисә бүтән эшләр башкарганда табылган археологик предметларны күрсәтелгән эшләрне башкаручы физик һәм (яисә) юридик затлар мәдәни мирас объектларын саклау буенча федераль орган билгеләгән тәртиптә мәҗбүри рәвештә дәүләткә тапшырырга тиеш.”;
б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:
“$2^1$. Табылган археологик мирас объекты турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы “Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында” Федераль законның $45^1$ статьясындагы 11 пунктында каралган мәгълүмат Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органына кергән көннән соң утыз көн эчендә археологик мирас объекты табылган җир кишәрлеге милекчесенә һәм

(яисә) җир кишәрлегеннән файдаланучыга, территориясендә әлеге археологик мирас объекты табылган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына җибәрә.";

4) 35 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Тарихи-мәдәни терәк план документлаштырылган һәм автоматлаштырылган рәвештә Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестры белешмәләре, тарихи-мәдәни тикшеренүләр материаллары, тарихи-архитектура терәк планнары һәм мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавына, аларны саклап калуга һәм алардан файдалануга караган башка белешмәләр нигезендә Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тарафыннан төзелә һәм алып барыла.";

5) 36 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 37 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4. Археологик мирас объектын физик саклап калуны тәэмин итү мөмкин булмаган очракта, бу археологик мирас объектын саклап калу дигәндә "Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында" Федераль законның $45^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә казылмалардан археологик предметларны тулысынча яисә өлешчә алып уздырыла торган коткару буенча археологик кыр эшләре аңлашыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 13 гыйнвары
№ 2-ТРЗ